Исполнительный комитет
Мунайкинского сельского поселения
Менделеевского муниципального района
Республики Татарстан
423652 д.Мунайка ,ул.Строителей, д.12
Тел.(885549)3-58-09

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Монай авыл башкарма комитеты
423652 Монай авылы, Тезучелэр
ур.12 нче йорт
Тел.(885549)3-58-09

15.05. 2023 ел № 7

Хайваннарны хуҗаларыннан башка кайтару тыела торган урыннарны билгеләү һәм хайваннарны хуҗаларыннан башка элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеген билгеләү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм хайваннар белән җаваплы эш итү турында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы Федераль законнарга, Менделеевск муниципаль районының Монай авыл җирлеге Уставына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Монай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган түбәндәге урыннарны билгеләргә:

- Балалар уен һәм спорт мәйданчыклары, актив спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар.
- Җәмәгать территорияләре (парклар, скверлар территорияләре, күпләп ял итү урыннары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буйлары).
- Мәгариф оешмалары һәм сәламәтлек саклау оешмалары территорияләре, күрсәтелгән оешмаларга якын территорияләр.
- Мәдәният һәм сәнгать объектларына якын территорияләр.
- Җәмәгать тукклануы оешмаларына, сәүдә объектларына якын территорияләр, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру урыннары.
- Йорт хайваннарын йөртү өчен билгеләнгән урыннар.
- Күп фатирлы йортларга якын территорияләр, аларда мондый йортларга хезмәт күрсәтү һәм эксплуатацияләү өчен билгеләнгән объектлар һәм бу территорияләрне төзекләндерү элементлары, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары), тротуарлар һәм автомобиль юллары, шул исәптән күп фатирлы йортларга якын территорияләргә керү өчен автомобиль юллары.

Зиратлар һәм мемориаль зоналар.

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Монай авыл җирлеге башлыгы Кириллов Руслан Михайловичны терлекләрне элекке яшәү урыннарына хуҗаларыннан башка кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле зат итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Менделеевск районы: Монай авылы, Төзүчеләр урамы, 12 йорт, Ленин урамы, 54 йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмати стендларда һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында www.mendeleeevsk.tatar.ru "Авыл җирлекләре" бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Монай авыл җирлеге башлыгы Р.М.Кириллов